ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Оешмалар мөлкәтенә салым турында” Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

“Оешмалар мөлкәтенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешенә (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9), аңа түбәндәге эчтәлекле 17 пункт өстәп, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

“17) исәпкә куелуыннан башлап 10 ел дәвамында оешма балансында исәптә торган мөлкәткә карата Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территория резидентлары булган оешмалар.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2016 елның 13 феврале
№ 4-ТРЗ